ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2007, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның бишенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә торган Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела торган Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлегенә кагылмый. Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасы сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлегенең оештыру һәм хокукый нигезләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.»;

2) 6 статьяда «федераль дәүләт хакимияте органнары» сүзләреннән соң «, Мәскәү шәһәре дәүләт хакимияте органнары һәм Мәскәү өлкәсе дәүләт хакимияте органнары, шулай ук Мәскәү шәһәрендә урнашкан Россия Федерациясе субъектлары вәкиллекләре, чит дәүләтләр вәкиллекләре һәм миссияләре, халыкара оешмалар, чит ил компанияләре, иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяның дүртенче өлешендә «йә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 11 статьяда:

а) 6 пунктта «Татарстан Республикасы турында, аның сәяси, социаль-икътисадый, мәдәни һәм рухи тормышы турында» сүзләрен «Татарстан Республикасына, аның сәяси, социаль-икътисадый, мәдәни һәм рухи тормышына кагылышлы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) мәдәни, фәнни багланышларны, мәгариф багланышларын һәм башка багланышларны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләр субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлегенә ярдәм итәләр;»;

5) 12 статьяның өченче өлешендәге 4 пунктында татарча текст үзгәрешсез кала;

6) 15 статьяның икенче өлешендә «юкка чыгару» сүзләрен «бетерү» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 25 июнь
№ 44- ТРЗ